# Кояш гомере телим әнием сиңа...

Әни... якты кояшка тиң, иң кдерле кеше. Дөньяда бәлки шулкадәр якын, ягымлы, ярдәмче кеше юктыр. Кеше кайда гына булса да, ни эшләсә дә, иң кирәк урын – әни янында, туган йортта. Ничә яшьтә булса да, һәркем үкереп елаган вакытта әнинең юатучы йомшак кулларын хәтерли. Башны сыйпап, бишек җырларын көләүче, кайгы-шатлыкларны уртаклашучы, гомер таянычы ул әни. Ул һәрберебез өчен иң кадерле, иң яхшы, иң матуры, гомумән, тормышта иң әһәмиятле кеше. “Әни, әнием, әнкәй” - дип назлап әйтәбез дә, күңелебездәге бөтен хис-кичерешләребезне шул гади сүзгә салабыз. Ә бит шушы өч хәрефтән торган сүзне күпме наз, җылылык һәм күңел тойгысы белән әйтәбез!

Хатын-кызның иң югары бурычы – әни булудыр, чөнки “әни” - бала әйткән беренче сүз. Бу сүз дөньяның күпчелек телләрендә бер үк төрле яңгырый һәм дөньяда иң якын, иң яраткан кешене атый.

Нәкъ менә шул сыйфатлар җәмгыятькә әниләр көнен игълан итәргә сәбәп булгандыр. Россия Федерациясе Президентының 1998 елның 30 гыйнварында чыккан 120 номерлы карары нигезендә, илебездә ноябрь аеның соңгы якшәмбесе ел саен “Әниләр көне” булып билгеләп үтелә. Быел ул 28 ноябрь көненә туры килә.

Илебездә билгеләп үтелә торган күпсанлы бәйрәмнәр арасында әниләр көне аерым урын алып тора. Бәйрәмнең максаты – хатын-кызга сакчыл караш традицияләрен хуплау, гаилә нигезләрен ныгыту, безнең тормышта төп кешенең – әнинең әһәмиятен аеруча билгеләп үтү. Бу бәйрәм беркемне дә битараф калдыра алмый. Нәкъ әниләр көнендә үз балаларына мәхәббәт, игелек, наз бүләк итүче барлык аналарга рәхмәт сүзләре әйтәсе килә. Тик нинди генә җылы сүзләр әйтмәсәк тә, җитмәс төсле... Әниләр көне – искиткеч көн. Безнең һәрберебез әниебезне искә төшерергә, аңа шалтыратырга, бәлки янына кайтып, аны котларга, аның сәламәтлеге һәм кәефе ничек булуы белән кызыксынырга тиешле көн!

Мөлаем һәм ягымлы кузле, акыллы, сабыр һәм түземле, шәфкатьле, авыр вакытларда арканы сыйпаучы кадерле куллы, боз эретерлек җылы сүзле, бала өчен кайгырып, төннәрен күз йоммаучы әниләребез, сезне бәйрәмегез белән чын йөрәктән котлыйбыз. Сезгә ныклы сәламәтлек, озын гомер, рухи көч, тормыш зирәклеге, сабырлык, бәхет, гаилә уңайлыгы телибез. Безгә биргән чиксез мәхәббәтегез, назыгыз һәм кайгыртуыгыз өчен рәхмәт!



## «Мәктәп экопатруле» конкурсы



Үсеп килүче буынны экологик тәрбияләү максатында Татарстан Республикасында «Мәктәп экопатруле» конкурсы һәм токның эшкәртелгән чыганакларын җыю акциясе уздырыла. «Мәктәп экопатруле» яшьләр проектлары конкурсы Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендә экологик проблемаларга игътибарны җәлеп итүгә юнәлдерелгән.

Экологик тематиканы алга җибәрү, актуаль экологик бурычларны хәл итү өлкәсендә фәнни-тикшеренү һәм проект активлыгын бүләкләү XI гасырның мөһим чакыруы булып тора. «Экологик патруль» проекты «Фән һәм технологияләр унеллыгы» инициативасы элементы булып тора һәм граждан фәненең бер юнәлешен үз эченә ала - мәктәп укучыларының әйләнә-тирә мохит торышын (туфрак, атмосфера, табигый сулар һәм явым-төшемнәрне) мониторинглау.

30 нчы ноябрь көнне В.П. Энгельгардт исемендәге астрономия обсерваториясендә бүләкләү тантанасы булды. Мәктәбебез 3 урынны яулады, шәхси беренчелектә 6 сыйныф укучысы Гомәрова Риана һәм Мөхәммәтова Сабина 1 һәм 3 урынны яуладылар. Аларны җиңүләре белән котлыйбыз.

## Рәсәй бөркетләре



Бүген ГББМУ "181 нче күп профильле мәктәп"тә истәлекле вакыйга, "Рәсәй бөркетләре" Бөтенрәсәй иҗтимагый оешмасы сафларына балалар хәрәкәтенең яшь катнашучыларын кабул итү булды. Безнең башлангыч мәктәп укучылары, бөтен ил буенча, "Рәсәй бөркетләре" берләшмәсенә керде. Рәсәй Балалар һәм Яшьләр берләшмәсе безнең мәктәп укучылары тулыланды. Тантанада мәктәп директоры Динә Альберт кызы яшь "Бөркетләр"не тантаналы рәвештә тәбрикләде. Тантанада шулай ук сыйныф җитәкчеләре, ата-аналар, "Юнармия" Бөтенрәсәй хәрәкәте әгъзалары катнашты. "Бөркетләр"ебезгә чын күңелдән бәхет, шатлык, уңышлар телибез!!!

## Куркынычсызлык беренче чиратта...



Бүген укучылар өчен мәктәптә 1-4 сыйныфларда юлларда куркынычсыз хәрәкәт буенча сөйләшүләр узды, балаларга тагын бер тапкыр куркынычсызлык кагыйдәләре турында искәртелде һәм яшь җәяүлеләр истәлекләре тапшырылды. Сөйләшүләрне Казан шәһәрендә территориаль идарәнең профилактика бүлегенең әйдәп баручы белгече Лилия Мәсгут кызы Мударисова уздырды.

## 4 ноябрь –Халыклар бердәмлеге көне





Халык бердәмлеге көне Русиядә 2005 елдан башлап ел саен 4 ноябрьдә билгеләнә. Бу бәйрәм 1612 елгы вакыйгалар хөрмәтенә билгеләнгән. Беренче милли хәрәкәтнең илне чит ил интервентларыннан азат итү омтылышларыннан соң икенчесе - Минин һәм Пожарский җитәкчелегендә формалаштырылган. Ул вакытка дәүләтнең көнбатыш чикләре һәм Мәскәү басып алына. Яңа азатлык хәрәкәтенең үзәге - Нижгар, ә аны тотучы - Кузьма Минин. 1611 елның көзендә нәкъ менә ул халыкка яңа милли хәрәкәт булдыру өчен акча җыюга чакыра. Хәрби җитәкче итеп кенәз Дмитрий Пожарский чакырыла. Төп көчләр Идел буе шәһәрләрендә һәм өязләрендә оештырылган. Милли состав максаты Мәскәүне интервентлардан азат итү һәм яңа хөкүмәт төзү була. Гаскәр 20 августта Мәскәүгә чыгыш ясый. Поляк гарнизоны, каты ачлыкка карамастан, тапшырудан баш тарта һәм батырлык белән саклана. Октябрь ахырында гына Пожарский сугышчылары Кытай-шәһәрне басып ала. Минин һәм Пожарскийның батырлыгы халык фольклорында да чагылыш тапкан. Калуга губернасында Нижгар гаскәре турында җырның варианты сакланган, анда "бай мещанин Кузьма Сухорукий улы" сәүдәгәрләргә бөтен нәрсәне сатырга, "көньяк найза, булат пычак" сатып алырга, воеводаны сайлап, "туган җирне", "анасы Мәскәүне" коткарарга мәгарлый. Кузьма "иң Сузмунд патшаны" да тулысынча алырга вәгъдә итә. "Яшьләрне воеводаны, дөньякүләм кенәз нәселеннән - Пожарскаго исемле кенәз Димитрияне" сайлыйлар. Мәскәүне алганнан соң кенәз Пожарский патша сайлау өчен шәһәрләрдән вәкилләрне чакыра. 1613 елның гыйнварында Земский соборы уза. Һәм Смута чоры бөтенләй тәмамланмаган булса да - шведлар, поляклар, литвалылар идарәне үз кулларына кайтару омтылышларын калдырмыйлар - ил эчендә инде бәхәсләр чыга.

4 ноябрь - Халык бердәмлеге көне. Ике йөз елдан соң дәүләт азат ителү истәлегенә Минин һәм Пожарскийның мәшһүр һәйкәле куела. Безнең көннәрдә Минин һәм Пожарский образы - Мәскәүнең төп визит карточкаларының берсе. Нәкъ менә ул 2012 елда яңадан торгызылган Россия тарихи җәмгыятенең символы итеп сайлана. Һәр ел Халык бердәмлеге көнендә монументка чәчәкләр куела. Моңа кадәр Дәүләт тарихи музее һәйкәлне торгызуга акча җыюны игълан иткән иде. Минин һәм Пожарский һәйкәле Мәскәүдә беренче зур скульптур һәйкәл булып тора. Һәйкәлгә 1818 нче елда салына.

## Минем әнием – укытучы!



Укытучы – иң кирәкле һөнәрләрнең берсе дип уйлыйм мин. Һөнәр генә түгел, аң - белем бирүче, тормыш алып барырга өйрәтүче, тәрбияләүче дә ул. Укытучы – мәктәптә икенче әни. Елмаеп каршы ала, яратып, озатып кала. Усаллардан яклый, ямьсез гамәл кылсаң, ачулана, гаебеңне аңлата. Укытучы – ул синең икенче фәрештәң.

Минем әнием дә укытучы. Ул төне буе йокламыйча дәфтәрләр тикшерә, дәрестән соң укучылар белән калып, өстәмә шөгыльләнә, олимпиадага әзерли, кичләрен чараларга репетицияләр ясата, журнал тутыра, билгеләр куя ... Мәктәптән кайтып кергәне юк дисәм дә, дөрес булыр, чөнки балаларны да, эшен дә бик ярата.

Ял көннәрендә дә тик утырмый, һаман эшли. Укучысы авырса, хәлен белешеп, шалтыратып тора яисә, белеме артка калмасын дип, укытучылардан биремнәр алып, аларга җибәрә. Берәр укытучы авырып китсә, аларның дәресләрен укыта. Ата – аналар җыелышына да, укытучылар утырышына да – барысына да бара, катнаша, чыгыш ясый. Шуннан тыш, үз белемен күтәрү максатында дистанцион курсларда укый, конкурсларда, конференцияләрдә катнаша, җиңүләр яулый. Тагын күпме документлар тутырасы, мәктәп газетасына нинди үзгәрешләр кертәсе, эш программаларын төгәллисе, дәресләргә әзерләнәсе – барысы да аның өстендә.

Минем әнием – бар яктан дә үрнәк кеше. Беренчедән, әнием эшеннән арып кайтса да, йорт эшләрен эшләргә дә өлгерә: ашарга пешерә, җыештыра... Кулыннан бар эш тә килә: бәләвен дә бәйли, тегә, тәмле тортлар да пешерә.

Әнием әби – бабамнарның да хәлен гел белеп тора, атна саен алар янына кайтабыз, хуҗалык эшләрендә булышабыз. Җәй көне йорт тирәбезне аллы – гөлле чәчәкләргә күмүче дә минем әнием. Бу эшләргә ул мине дә өйрәтә. “Егет кешегә 70 төрле һөнәр дә аз”, - ди ул. Икенчедән, әнием әтиемне, мине бик ярата. Без авырсак, ул төннәр буе янибызда утыра, дәвалый. Авыр вакытларда безгә ярдәм итә, юата, алтын киңәшләрен бирә. Якшәмбе көннәрендә, бәйрәмнәрдә өстәл тутырып сый әзерли. Өченчедән, миңа, тормышта зур үрләр яулар өчен тырышып укырга, ялкауланмаска, хәзердән үк алдыңа максат куярга дип, өйрәтә. Мин дә укытучы әниемә карап, тыңлаучан, акыллы, тәртипле һәм эшчән булып үсәргә тырышам.

Укытучы – иң тырыш, эш сөючән, уңган кеше. Ә укытучы әни кеше – таләпчән, ярдәмчел, иң якын, газиз кеше. Өстәвенә ул нинди генә эш башкармасын, барысына дө өлгерергә, барысын да җиренә җиткереп вакытында тапшырырга, бөтенесен дә белергә, булдырырга тырыша. Җир йөзендәге барлык әниләргә укытучы малаеннан ныклы сәламәтлек, авыр хезмәтләрендә зур унышлар һәм сабырлык, уңышлар телим!

## Мәктәбем остазы



Кем ул остаз?

С.И. Ожегов сүзлегендә: «Остаз – укытучы һәм тәрбияче, җитәкче»-дип әйтелә. Минемчә, остаз ул укытучы һәм ниндидер эшчәнлекнең җитәкчесе генә дә түгел, ул безгә һәрвакыт башлангычларыбызда үсеш алырга ярдәм итүче, куллар төшкән вакытта, кайвакыт үз хаталарыннан чыгып, үз тәҗрибәсе турында сөйләп ярдәм итүче кеше. Остазның кәефе яхшы, кайвакыт кәефсез дә булырга мөмкин, әмма нәкъ менә ул, бернәрсәгә карамастан, безгә сүз, эш белән ярдәм итәргә әзер, безне дәртләндерүче һәм хыялларыбызга ышанырга ярдәм итүче.

Минем мәктәптә үз өлкәсендә белемле, игътибарлы, компетентлы укытучыларым күп, әмма мин үз остазым итеп педагог - оештыручы Закамская Надежда Анатольевнаны саныйм. Ул Казан шәһәре Совет районының 181нче мәктәбендә белем алучылар Советы остазы, аның составына мин дә керәм. Ул безгә чараларны оештыруда ярдәм итә, проектларны тиз һәм нәтиҗәле тормышка ашыру буенча үз тәҗрибәсе белән уртаклаша, ниятләнгәнне иҗади тормышка ашыруга юнәлтә.

Минем остазымның төп сыйфатлары- хәлне тыңлау һәм анализлау осталыгы. Надежда Анатольевна һәрвакыт минем идеяләремне тыңларга, проблемаларымны чишәргә әзер, эш белән мәшгуль булган чакларында да һәрвакыт игелекле, ярдәмчел, игътибарлы булып кала. Күпме бәхәсле минутлар булды, ул аларны вакытында чишәргә ярдәм итте. Безнең остаз проблемаларны чишү белән генә түгел, ә укучылар советы эшчәнлегенең сыйфатын үстерүгә дә ярдәм итә. Ул идеяләре белән бүлешә, аларны тормышка ашыру юлларын күрсәтә, шулай ук киләчәк проектларга планнар кору турында фикер алышуда катнаша. Надежда Анатольевна ярдәмендә без үз тырышлыкларыбызның нәтиҗәләрен коллектив һәм шәхси нәтиҗәләр аша күрәбез. Остазыбыз җитәкчелегендә без күп төрле юнәлешләрне үстерәбез, ә аннары бәйгеләрдә катнашабыз. Надежда Анатольевна безне, ситуациягә тиз яраклашырга, аралашу күнекмәләрен һәм бөтен коллектив белән бергәләп эшләргә, шулай ук лидерлык сыйфатларын үстерергә өйрәтә. Быел без оештыручы педагог катнашын таләп итә торган бер проблема белән очраштык. Озак сәгатьләр буе фикер алышканнан соң, Надежда Анатольевна, килеп туган хәлдән чыгу юлын табарга тырышуларыбызны күреп, мәктәп администрациясенә проблеманы хәл итү буенча мөрәҗәгать итте, шуның белән мәктәп укучылары советы хәл иткән бурычларның әһәмиятен күрсәтте. Бу вакыт эчендә без мондый ситуацияләрдә үзебезне ничек тотарга кирәклеген аңладык, уртак фикергә килдек, үзара аңлашуга ирештек, шулай ук проблеманы бер зур команда белән хәл иттек. Безнең өчен бу мәктәп укучыларының аралашу дәресе генә түгел, ә мәктәп үзидарәсенең зур җиңүе дә булды. Безнең остаз безнең ышанычлы җилкәбез генә түгел, ә үрнәк һәм илһамландыручы. Аның киңәшләре безгә идеяләрне тормышка ашыруда гына түгел, ә коллективны берләштерүдә дә ярдәм итте. Аның ярдәме безгә яңа башлангычлар өчен үзебезне ышанычлы хис итәргә ярдәм итә, шулай ук тагын да күбрәк эшләргә этәрә.

Мин остазыма зур рәхмәтемне белдерәсем килә, чөнки ул булмаса, без ирешкән нәтиҗәләрнең берсе дә булмас иде: безнең җиңүләребез, безнең бәхетле йөзләребез, безнең дәрт һәм яңалыкка омтылышыбыз...

Надежда Анатольевна, сезнең хезмәтегезнең бәясе бихисап күп, Сез безгә бу тормышта үзебезне табарга ярдәм итәсез һәм сезнең тырышлыгыгыз зур хөрмәткә лаек. Надежда Анатольевна, авыр минутларда кулларыгызны төшермәгәнегез һәм безгә ярдәм кулы сузганыгыз өчен Рәхмәт сезгә!

Буторина Анастасия Сергеевна, 10А сыйныф укучысы

**Редакциянең адресы:**420101, Казан шәһәре, Тулпар урамы, 2

Тел. 89050229576 **Тираж** – 50 экз.

**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова А.Ф.

**Редколлегия әгъзалары**:
Хәмидуллина Гөлинә, Гөмарова Риана, Сафина, Самира, Хәзиев Әмин